| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2021 Баулы шәһәре № 36

Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге «Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге «Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 159 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 25 февралендәге 196 номерлы, 2020 елның 29 маендагы 264 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 16 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләргн кертергә:

16нчы статьяның 4нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатында, әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар (тиешле вазыйфаны биләгән чорда)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин